ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» декабрь 2020 ел. № 422

2020 елда яклар килешүе буенча контрактларны (шартнамәләрне) үтәү кысаларында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль заказчыларына контрактны үтәү срокларын яисә контракт бәясен үзгәртү хокукын бирү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 112 статьясындагы 65 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20.03.2020 № 620-р күрсәтмәсе белән расланган яңа коронавировка инфекциясе таралуга, нефтькә һәм доллар курсына бәяләр волатильлегенә бәйле вәзгыятьнең начараюы шартларында Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү чаралары планының 3.12 пунктын үтәү өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 апрелендәге 768-р номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 мартындагы 620-р номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү турында» күрсәтмәсе, «2020 елда яклар килешүе буенча контрактларны үтәү кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт заказчыларына контрактны үтәү срокларын яки контракт бәясен үзгәртү хокукын бирү турынд» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 маендагы 921-р номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен төзелгән контрактларга (килешүләргә) карата, яклар килешүе буенча, 2019-nCoV китереп чыгарган яңа коронавируслы инфекция таралуга бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән очракларда, аны үтәү мөмкин булмауга китерә торган контракт ягыннан бәйле булмаган шартлар барлыкка килсә, контрактны үтәү срокларына, һәм (яисә) контрактның бәясе, һәм (яисә) товар берәмлеге, эш, хезмәт күрсәтүләр бәяләре үзгәрешләр кертелә (дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 24 өлешендә каралган очракта) дип билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**